КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 30 сентябрь г.Казань № 6-1893

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. Татарстан Республикасында 2020 елның 10 октябрендә «Татарстан кроссы – 2020» республика массакүләм ярышларын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, «Татарстан кроссы – 2020» республика массакүләм ярышларында укучылар, студентлар, предприятиеләр һәм оешмалар эшчеләре һәм хезмәткәрләре, балалар һәм пенсионерлар катнашуны тәэмин итәргә;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, ярышта катнашу өчен төрле яшьтәге шәһәр халкын киң җәлеп итеп, Казан шәһәрендә 2020 елның 10 октябрендә «Милләт кроссы» Бөтенроссия йөгерү көнен әзерләү һәм үткәрү эшен оештырырга.

3. Башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасының теләсә кайсы милек рәвешләрендәге предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә әлеге ярышларда үз хезмәткәрләре катнашуны оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин